Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Илтерәк авыл җирлеге башлыгы

# КАРАР

26.11.2021 ел. №12

Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлегенең
Тарханка авылында халык җыенын гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе
буенча билгеләп кую турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.11.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Илтерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,
КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ильдеряк авыл җирлеге башлыгының «Аксубай муниципаль районы Тарханка авыл җирлегенең Тарханка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» гы 7 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. ТР, Аксубай районы, Тарханка авылы, Көнбатыш урамы, 7 йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында 2021 елның 10 декабрендә 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Тарханка авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының билгеләргә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән сез риза буласызмы?

**1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- авыл эчендәге автомобиль юлларын кышкы чорда торак пунктта тоту (килешү буенча эш өчен түләү).

**2) Әлеге кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- МТЗ-320.4 М тракторына асылмалы кар чистарткыч сатып алу.;
- электр белән тәэмин итү челтәренә тоташтырылган яктылык күрсәткечләрен сатып алу.

**3) җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны җиһазландыруны оештыру, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына иректе үтеп керүен тәэмин итүне дә кертеп**

- массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерү (яр буе).

**4) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:**

- зиратларны төзекләндерү һәм карап тоту.

**5) ККҖны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**

- контейнерлар сатып алу, контейнер киртәләр төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

**6) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:**

- Тарханка авылында су үткәргеч челтәрләрен ремонтлау, суэтем башнясын койма белән әйләндереп алу (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)).

**7) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:**

- ут сүндергечләр сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, әлеге карарны авыл җирлеге халкы күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм такталарда элеп кую юлы белән, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

ТР Аксубай муниципаль районы
Иске Илтерәк авыл җирлеге башлыгы: С. М. Маклаков